ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 431 от «16» 12 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 февралендәге 94 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 07 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон (01.05.2016 редакциясендә), РФ Хөкүмәтенең «2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасы турында» 2012 елның 14 июлендәге № 717 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкының шәхси ярдәмче хуҗалыкларын үстерү концепциясен раслау турында» 2006 елның 30 мартындагы 136 номерлы карары нигезендә Татарстан Республиксы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 февралендәге «2018-2022 елларга Мамадыш муниципаль районында кече, урта эшкуарлыкны һәм кече хуҗалыкларны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 94 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Карарга кушымтаның 2 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«урта предприятиеләр өчен хезмәткәрләрнең уртача исемлек санының башка чик әһәмияте 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 2.1 һәм 2.2 пунктлары нигезендә билгеләнмәгән булса, уртача предприятиеләр өчен йөз кешедән ике йөз илле кешегә кадәр».

0000011517

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче О.Н.Павлов